# Мәйдан Чаллы

әдәби-нәфис,
иҗтимагый
журнал

3 / 2014
март

Вахит ИМАМОВ



4 612750 670196

## Вахит ИМАМОВ

Вахит Шәих (Шәйхенур) улы Имамов 1954 елның 18 мартында Актаныш районы Иске Байсар авылында дөньяга килә. Туган авылында 1971 елда урта мәктәпне тәмамлый. Шул елның көзендә Казанга килеп, моторлар төзү берләшмәсендә токарь булып эшли башлый. 1973 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1975 елдан ул Балык Бистәсе районы газетасында әдәби хезмәткәр. Армия сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң шул ук газета редакциясендә хатлар бүлеге мөдире. 1982 елда гаиләсе белән Чаллы каласына күченә. Урта мәктәптә тарих фәнен укыта, 5 ел буена «КАМАЗ»ның Пресс-рам заводында мастер, участок башлыгы, өлкән диспетчер. 1991 елдан соң ул үзе үк оештырган «КАМАЗ» газета-китап нәшрияты»нда баш мөхәррир. 1997 елның языннан бирле Чаллы язучылар оешмасын җитәкли, 2005 елдан башлап «Мәйдан» журналының баш редакторы.

Беренче әдәби әсәрләре район һәм республика газеталарында 1971–1972



# Вахит ИМАМОВ

елларда ук күренә башлый. Казан университетында укыган чагында беренче повестьларын язып, аларны Мөхәммәт Мәһдиевка укытып карый һәм хуплау сүзләрен ишетә. Аннан соңгы остазлары дип Гариф Ахунов белән Аяз Гыйләҗевны саный. «Ир канаты» дип исемләнгән тәүге китабы 1988 елда дөнья күрә. 1991 елда икенче җыентыгы – «Нәзер» басылып чыга. Китаптагы «Нәзер» повесте һәм «Өмет» хикәясе буенча Татарстан телевидениесе шул ук исемдәге нәфис фильмнар төшерә. Төп рольләрдә Рәшидә Җиһаншина, Шамил Бариев кебек күренекле артистлар уйный, фильмнар республика телевидениесе тарафыннан кат-кат күрсәтелә.

Иҗат эшеннән тыш, В.Имамов татар халкы тарихының ак тапларын ачыклау өлкәсендә дә туктаусыз хезмәт куя. 1982 елдан башлап, 12 ел буена җәй һәм көз айларында Уфа, Оренбург, Уральск, Екатеринбург, Белорет, Мәскәү калаларының архивларына һәм сирәк кульъязмалар саклануча бүлекләренә эзләнергә йөри. Нәтиҗәдә, 1993 елда «Онытылган тарих» дип исемләнгән һәм татар халкының 1552–1755 елларда алып барган милли-азатлык яуларына багышланган беренче тарихи хезмәте дөнья күрә. 1994 елда автор аны үзе үк рус теленә тәрҗемә итә һәм «Запрятанная история татар» дип аталган бу китабы 400000 данә тираж белән басылып, бөтен Рәсәй буйлап таратыла. Шул ук елда В.Имамов «Сәет батыр» һәм «Татарлар Пугачев явында» исемле тарихи романнарын иҗат итә, «Сәет батыр» китабы 90000 данә итеп нәшер ителә. Шушы хезмәте өчен В.Имамов 1995 елда Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек була.

2000 елда В.Имамов укучыларны үзенең «Утлы дала» дигән яңа тарихи романының беренче китабы белән сөендерде. 2002 елда «Мәйдан» журналында аның «Тозлы яра» дип исемләнгән өр-яңа романы дөнья күрде. В.Имамов үзенең 50 яшьлеген тагын «Могикан», «Япун татары», «Тозлы яра», «Татар яугирләре» атлы яңа китаплары белән дә каршылады. Казан шәһәренең 1000 еллыгы уңаеннан «Казан дастаны» исемле тарихи роман язды, әсәр Б.Хәмидуллин тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителде һәм «Казанская крепость» буларак нәшер ителде. 2011 елда В.Имамов «Утлы дала» тарихи романының 2 нче китабын тәмамлады һәм бераздан аның I һәм II томнары бер китап булып, Казан китап нәшриятында нәшер ителде.

В.Имамов 1992 елдан башлап Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 2002 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. В.Имамовның «Запрятанная история татар» китабы украин, казах, әзербайҗан, төрек, алман, инглиз, француз, һинд, кытай телләренә тәрҗемә ителде, китапларының гомуми тиражы бер миллион ярым данәдән дә артты. «Утлы дала» романы өчен В.Имамов быел республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде.